| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

29.01.2021　　　　　　　　　　　　№ 83-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2013 елның 19 сентябрендәге 1195-п номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2020 елга һәм 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе уртак коллегиясе Беркетмәсенең 24 һәм 25 пунктларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең “Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында” 2013 елның 19 сентябрендәге 1195-п номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә (2015 елның 31 декабрендәге 1676-п номерлы, 2016 елның 12 маендагы 575-п номерлы, 2017 елның 14 мартындагы 267 номерлы, 2017 елның 29 августындагы 1025-п номерлы, 2018 елның 29 гыйнварындагы 71-п номерлы, 2019 елның 2 сентябрендәге 1020-п номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** Тәртипнең 2 бүлегендәге 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле к) пунктчасы белән тулыландырырга:

“к) мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка түләүләр буенча бурычлары булмавы турында салым органы белешмәсе (белешмәләре).”;

**1.2.** 2.4 пунктны түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац белән тулыландырырга:

“ - мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булуы.”.

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында _бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов